**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 7 август | № 577

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 22 март, 233 нче, 2013 ел, 29 август, 613 нче, 2014 ел, 25 июнь, 435 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Пляжлар өчен су объектларында кешеләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итү өлешендә әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән таләпләргә туры килми торган, су объекты акваториясе тоташкан яр участоклары коену өчен җиһазландырылмаган һәм куркыныч урыннар булып тора.

Җиһазландырылмаган һәм куркыныч урыннарда коену тыела.

Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясы нигезендә коену өчен җиһазландырылмаган, куркыныч һәм тыелган урыннар турында мәгълүматны халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары аша, яр буенча махсус мәгълүмат билгеләре урнаштыру юлы белән, шулай ук бүтән ысуллары белән җиткерә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\577.docx